| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21.11.2018 Казан ш. № 10-52/кс

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2017 елның 24 ноябрендәге 10-48/кс номерлы карары белән билгеләнгән "Үзәк торак-коммуналь идарәсе" федераль дәүләт бюджет учреждениесенең эчәргә яраклы суга, техник суга, салкын суны транспортировкалауга һәм агып төшә торган суларны транспортировкалауга озак вакытка исәпләнгән тарифларын 2019 елга үзгәртү турында

"Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару турында" 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында" 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Тарифлар буенча федераль хезмәтнең "Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләп чыгару буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында" 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы, "Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә җайга салына торган тарифларны билгеләү регламентын раслау турында" 2014 елның 16 июлендәге 1154-э номерлы боерыклары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә таянып, "Үзәк торак-коммуналь идарәсе" федераль дәүләт бюджет учреждениесенең эчәргә яраклы суга, техник суга, салкын суны транспортировкалауга һәм агып төшә торган суларны транспортировкалауга озак вакытка исәпләнгән тарифларын һәм таләп ителгән тулаем табышын үзгәртү максатларында Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының "2018 – 2020 елларга "Үзәк торак-коммуналь идарәсе" федераль дәүләт бюджет учреждениесе өчен эчәргә яраклы суга, техник суга, салкын суны

транспортировкалауга һәм агып төшә торган суларны транспортировкалауга тарифлар билгеләү турында" 2017 елның 24 ноябрендәге 10-48/кс номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырылган көннән соң 10 көн эчендә үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
2017 елның 24 ноябрендәге 10-48/кс
номерлы карарына 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
2018 елның 21 ноябрендәге 10-52/кс
номерлы карары редакциясендә)

Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы "Үзәк торак-коммуналь идарәсе" федераль дәүләт бюджет учреждениесе өчен 2018 – 2020 елларга, календарь бүленештә күрсәтеп, эчәргә яраклы суга, техник суга, салкын суны транспортировкалауга һәм агып төшә торган суларны транспортировкалауга тарифлар

| т/б № | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы оешманың исеме | Ел | Эчәргә яраклы суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | Техник суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | Салкын суны транспортировкалауга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | Агып төшә торган суларны транспортировкалауга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | "Үзәк торак-коммуналь идарәсе" федераль дәүләт бюджет учреждениесе | | | | | |
| 1.1 | "Казан шәһәре" муниципаль берәмлеге кулланучылары | | | | | |
| 1.1.1 | Халык (тарифлар НДСны исәпкә алып күрсәтелгән)* | 2018 елның 1 гыйнварыннан 2018 елның 30 июненә кадәр | 28,65 | | | |
| | | 2018 елның 1 июленнән алып | 29,86 | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2018 елның 31 декабренә кадәр | | | | |
| | | 2019 елның 1 гыйнварыннан 2019 елның 30 июненә кадәр | 30,37 | | | |
| | | 2019 елның 1 июленнән 2019 елның 31 декабренә кадәр | 31,10 | | | |
| | | 2020 елның 1 гыйнварыннан 2020 елның 30 июненә кадәр | 31,10 | | | |
| | | 2020 елның 1 июленнән 2020 елның 31 декабренә кадәр | 31,98 | | | |
| 1.1.2 | Башка кулланучылар (тарифлар НДСны исәпкә алмыйча күрсәтелгән) | 2018 елның 1 гыйнварыннан 2018 елның 30 июненә кадәр | 24,28 | | 9,45 | 6,60 |
| | | 2018 елның 1 июленнән алып 2018 елның 31 декабренә кадәр | 25,31 | | 9,85 | 6,88 |
| | | 2019 елның 1 гыйнварыннан 2019 елның 30 июненә кадәр | 25,31 | | 9,85 | 6,88 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2019 елның 1 июленнән 2019 елның 31 декабренә кадәр | 25,92 | | 10,13 | 7,08 |
| | | 2020 елның 1 гыйнварыннан 2020 елның 30 июненә кадәр | 25,92 | | 10,13 | 7,08 |
| | | 2020 елның 1 июленнән 2020 елның 31 декабренә кадәр | 26,65 | | 10,36 | 7,22 |
| 1.2 | Биектау муниципаль районы кулланучылары (тарифлар НДСны исәпкә алмыйча күрсәтелгән) | 2018 елның 1 гыйнварыннан 2018 елның 30 июненә кадәр | | 28,52 | | |
| | | 2018 елның 1 июленнән алып 2018 елның 31 декабренә кадәр | | 29,74 | | |
| | | 2019 елның 1 гыйнварыннан 2019 елның 30 июненә кадәр | | 29,74 | | |
| | | 2019 елның 1 июленнән 2019 елның 31 декабренә кадәр | | 30,49 | | |
| | | 2020 елның 1 гыйнварыннан | | 30,49 | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | алып 2020 елның 30 июненә кадәр | | | | |
| | | 2020 елның 1 июленнән алып 2020 елның 31 декабренә кадәр | | 31,27 | | |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
тарифларны кабул итүне оештыру,
тикшерү һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
2017 елның 24 ноябрендәге 10-48/кс
номерлы карарына 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
2018 елның 21 ноябрендәге 10-52/кс
номерлы карары редакциясендә)

"Үзәк торак-коммуналь идарәсе" федераль дәүләт бюджет учреждениесе өчен 2018 – 2020 елларга эчәргә яраклы суга, техник суга, салкын суны транспортировкалауга һәм агып төшә торган суларны транспортировкалауга тарифларны җайга салуның озак вакытка каралган параметрлары

| № т/б | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы оешманың исеме, тариф төре | Ел | Операцион чыгымнарның нигез дәрәҗәсе | Операцион чыгымнарның нәтиҗәлелеге индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | су югалту дәрәҗәсе | электр энергиясенең чагыштырма кулланылышы |
| | | | мең сум | % | % | % | кВт.сәг./куб. м |
| 1 | "Үзәк торак-коммуналь идарәсе" федераль дәүләт бюджет учреждениесе | | | | | | |
| 1.1 | "Казан шәһәре" муниципаль берәмлеге кулланучылары | | | | | | |
| 1.1.1 | Эчәргә яраклы су | 2018 | 581,71 | 1 | - | 11,7 | 1,26 |
| | | 2019 | 603,22 | 1 | - | 11,7 | 1,26 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2020 | 617,49 | 1 | - | 11,7 | 1,26 |
| 1.1.2 | Салкын суны транспортировкалау | 2018 | 2090,76 | 1 | - | 8,17 | 0,38 |
| | | 2019 | 2165,57 | 1 | - | 8,17 | 0,38 |
| | | 2020 | 2216,81 | 1 | - | 8,17 | 0,38 |
| 1.1.3 | Агып төшә торган суларны транспортировкалау | 2018 | 1675,15 | 1 | - | - | 0,19 |
| | | 2019 | 1734,67 | 1 | - | - | 0,19 |
| | | 2020 | 1775,72 | 1 | - | - | 0,19 |
| 1.2 | Биектау муниицfolkпаль районы кулланучылары | | | | | | |
| 1.2.1 | Техник су | 2018 | 359,51 | 1 | - | 5,2 | 1,58 |
| | | 2019 | 358,67 | 1 | - | 5,2 | 1,58 |
| | | 2020 | 367,16 | 1 | - | 5,2 | 1,58 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
тарифларны кабул итүне оештыру,
тикшерү һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге